Бүгенге санда



Өлкәннәр ункөнлеге маршрутлары буйлап. 2 бит.


# Дуслык

Дружба

1931 елның 9 июленнән бирле чыга

Нурлат шәһәре һәм Нурлат районы газетасы

Җомга 9 октябрь 2015 ел

№74 (10603)


10 октябрьгә һава торышы: болытлы һава, кар, җил көньяк-көнбатыштан, 3-6 м/с; температура көндез 0°С, төнлә -3°С

## КОТЛАУ

**Хөрмәтле аграр тармак хезмәтчәннәре, агросәнәгать комплексы ветераннары!**

Авыл хуҗалыгы һәм эшкәртү сәнәгате хезмәтчәннәре көне уңаеннан ихлас котлауларны кабул итегез. Сез үзегезнең карусыз хезмәтегез белән республикабызны, шул исәптән районыбызны үзебездә җитештерелгән сыйфатлы продукция белән тәэмин итүгә, төбәгебезнең икътисадый үсешенә саллы өлеш кертәсез. Бүгенге көндә Татарстан Россия төбәкләре арасында тулаем авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерү буенча өченче, сөт җитештерүдә беренче, ит җитештерүдә өченче урында икән, монда, һичшиксез, Нурлат игенчеләре һәм терлекчеләренең дә лаеклы өлеше бар.

Соңгы биш елда табигать сынауларына карамастан, сез районның авыл хуҗалыгы тармагында тотрыклылыкны саклап кала алдыгыз, һәм бүгенге көндә ул район икътисадындагы нәтиҗәле юнәлешләрнең берсе булып тора. Авыл хуҗалыгы продукциясе җитештерүне арттыру, эшкәртү сәнәгатен киңәйтү, хуҗалык итүнең кече формалары эшен активлаштыру аша җитди икътисадый һәм социаль бурычлар хәл ителә. Шуңа сезнең фидакарь хезмәтегез алдында баш иеп, без бүген олы рәхмәтебезне юллыйбыз.

Бәйрәмегез уңаеннан сезгә һәм гаиләләрегезгә иминлек телим, йортларыгызда муллык һәм тынычлык хакимлек итсен, эшләрегез уң, көннәрегез аяз булсын.

**Равил Кузюров,**
**Нурлат муниципаль районы һәм шәһәре башлыгы.**

## УКЫГЫЗ!

**“Герой булырга хаклы ул”**

*Кем ул алтынчы герой? һәм, гомумән, ул әлеге югары исемне алганмы? Маргарита Литта үткәргән журналист эзләнүе шул сорауларга ачыклык кертә.*

*4нче бит.*

# Табын күрке – икмәк



Автор фотосы

**Район игенчеләренең көнне төнгә ялгап башкарган фидакарь хезмәт җимеше – икмәк. Ә аны “Здоровье” җәмгыятендә тәмле һәм хуш исле итеп пешерә беләләр. Ипи пешерү осталары Лариса Помендеева белән Нина Захарова көн саен район халкын йомшак ипи белән сөендерә алуларына шат.**

**Чәршәмбе көнне Казанда Авыл хуҗалыгы һәм җитештерү сәнәгате хезмәтчәннәре көне уңаеннан Татарстан Президенты Рөстәм Миннехановның бәйрәм кабул итүендә нурлатлылар да катнашты.**

Ә “Сөләйманов Ә.И” КФХсы һәм “Нурлат сөте” җәмгыяте механизаторлары Хәкимулла Нуретдинов белән Сергей Ватранов республиканың алдынгы игенчеләре арасында хөрмәтләнделәр.

– Президент кабул итүе игенченең хезмәтенә дан җырлаучы, икмәк, сөт, ит җитештерүчеләрнең хезмәтен олылаучы гаҗәеп зур бәйрәм булып узды, - дип тәэсирләре белән уртаклашты нурлатлылар.

Ә бәйрәм авыл хуҗалыгы тармагының еллык хезмәтенә билгеле бер нәтиҗәләр ясау һәм алда торган бурычларны билгеләү өчен дә яхшы форсат әле ул.

– Районның барлык хуҗалыклары да техника ремонты, язгы чәчү, азык әзерләү, урып-җыю кебек мөһим кампанияләр вакытында эшләрне оптималь оештырып, куелган бурычларны вакытында һәм тиешенчә башкарып чыктылар, - ди районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе начальнигы Ислам Сафиуллин. – Быел игенчеләребез тырышлыгы белән 80 мең тоннадан артыграк икмәк җыеп алынды, бер гектарга уртача уңыш 20,2 центнер тәшкил итте. Терлекчелек комплексында быел продукция алу узган елгы белән чагыштырганда арту ягында, 9 айда 1379 тонна ит, 24630 тонна сөт җитештерелде, шикәр чөгендере мул уңыш белән сөендерә. Район аграрийлары быел зур азык запасы әзерләде, киләсе ел уңышына яхшы нигез салынды.

Әмма авыл кешесе өчен күзгә эшләр тәмамланмады әле. Район механизаторлары бу көннәрдә дә татлы тамыр казу, көнбагыш суктыруны дәвам итә, туңга сөрү бара, әле бөртеккә диган кукурузны җыеп аласы бар. Кышлатуны мул продукция алып үткәрү бурычы куела. Һәм авыл кешесе бу эшләрне тәмамламыйча, кышка тыныч күңел белән кермәячәген белә. Шуңа да бәйрәмнәре дә тынгысыз хезмәт белән үтә аларның.

**Лилия МӨБАРӘКШИНА**

*Бәйрәмгә һәм хезмәт кешеләренә багышланган сәхифәбез – 3нче биттә.*

# Ягу сезонын иртә башлау отышлы



ШӘҺӘР БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ҖИТӘКЧЕСЕ НӘГЫЙМ САФИУЛЛИН

**Әгәр берничә көн дәвамында һава температурасы +8 градустан югары күтәрелмәсә, регионнарда өйләргә һәм учреждениеләргә җылылык бирелә. Нурлатта җылылык 1 октябрьдә бирелде, ул көнне урамда +13 градус иде.**

– Бүгенге көнгә барлык купфатирлы йортларга, балалар бакчаларына, мәктәпләргә җылылык бирелгән, – диде шәһәр башкарма комитеты җитәкчесе Нәгыйм Сафиуллин. – Җылылыкны вакытыннан алда бирүнең берничә уңай ягы бар. Торак милекчеләре ширкәтләре җәй көне батареяларны юдырдылар, хәзер, су агып чыга калса, суыклар башланганчы эшермәләрне ачып, кимчелекләрне бетерергә мөмкин. Мәсәлән, капиталь ремонт ясалган йортларның берсендә шундый хәл күзәтелгән иде. Иң мөһиме, каты салкыннар башланганчы, кимчелекләрне ачыклап, аларны төзәтү.

**С.СӘМӘРХАНОВА** сөйләште


**2016 ЕЛНЫҢ 1нче ЯРТЫЕЛЛЫГЫНА “ДУСЛЫК”КА ЯЗЫЛУНЫҢ УҢАЙЛЫ ЮЛЫН САЙЛАГЫЗ!**

Дуслык Дружба Туслăх



*Өйгә килүен телисез икән, сезнең өчен* **традицион әбунә – 528 сум**



*Электрон почтага* **– он-лайн әбунә – 300 сум**



*Редакциядән килеп алсагыз* **– альтернатив әбунә – 330 сум**

**ҺӘРЧАК БЕЗНЕҢ БЕЛӘН БУЛЫГЫЗ, НУРЛАТ ВАКЫЙГАЛАРЫННАН ХӘБӘРДАР ТОРЫГЫЗ!**

# Комбайнчы кыз Оля




СЕРГЕЙ УФИМОВ БЫЕЛ УРАККА КЫЗЫ ОЛЯ БЕЛӘН ЧЫКТЫ

**Гәйтәннән Оля Уфимова белән уракның иң кызу көннәрендә таныштык.**

Комбайнчы ярдәмчесе булып эшләүче кеч-кенә генә буйлы кызның хәрәкәтләренә күз иярми, кай арада кабинага менеп китә, аннан җәһәт кенә кулына ачкычын алып төшеп тә өлгерә. Сөйләшә башлагач исә аның елмаюыннан бөтен басуга нур чәчелгәндәй була.

– 10нчы сыйныфка барам. Басуга быел беренче генә чыктым әле. Арыйм дип әйтмәс идем, киресенчә, бик рәхәт, - дип җавапны кыска тота кыз.

Кыр корабына комбайнчы ярдәмчесе буларак беренче генә утыруы булса да, техника белән кызыксынуы байтактан килә икән инде.

– Машина йөртергә дә күптән өйрәнде, быел хәтта йөк машинасы руле артына да утырды, - ди әнисе. Ә техникага мәхәббәт, сүз дә юк, әтисе Сергей Уфимовтан килә. Гомере буена төрле техникада эшләгән механизатор бүгенге көндә "Сөләйманов Ә.И" КФХсында урып-җыю комбайнын иярли, ел да матур күрсәткечләр белән сөендерә. Быел исә басуга кызы Оляны да алып чыгарга карар кылган, чөнки кызының кулы эшкә ятып тора, техника серләрен дә бик теләп өйрәнә, өстәвенә, тырышлыгы да зур.

Әниләре Наталья Семеновна да кызының бу теләгенә каршы килмәгән, аның техника тирәсендә кайнашуын да хуплый.

– Әгәр кызыксынып эшли икән, нигә каршы килим, шатланып кына торам. Дөрес, урак вакытында комбайнчыларга җиңел түгел: иртәнге 5тән китеп, төн уртасына кадәр эшләгән чаклары күп булды. Әмма үзе бер дә зарланмады. Бер караганда, эшкә өйрәнеп үсүе бер дә начар түгел, – ди ул.

Ә Оля үзе уракта эшләп алган беренче хезмәт хакын шоферлыкка укуга тотмакчы була. Машина йөртүче хокукы алып, үзе комбайн руле артында мәстәкыйль басу-кырларның инлисе килә аның. Бар гомерен җиргә багышлаган әтисе Сергей Геннадьевич кебек.

# Өлкән буынга алмаш килә

**Игенче хезмәте җиңел түгел – район механизаторларының күбесенә иртә яздан караңгы көзгә кадәр басу-кырлардан кайтып кермичә тир түгәргә туры килә.**

"Нурлат сөте" хуҗалыгы тракторчысы Сергей Короткин да быел яз башында ук үзенең "Маккормигы" белән җир дисклауга чыкты, аннан чәчүдә мәшгуль булды. Шытымнар баш төрткәч, үсемлекләрне саклау чараларына кушылды, шуннан печән, азык әзерләү ялганып китте. Һәм менә август азагыннан Сергей Петрович – көзге җир сөрүдә. Хуҗалыкка килгән 10 ел эчендә механизатор әнә шулай бер участоктан икенчесенә күчеп эшләвен дәвам итә. Кышын да тик утырмый: ремонтка да чыгарга туры килә, узган ел "МТЗ-1221"гә утырып, терлекчелек тармагында да эшләп алды әле.

– Эш җиңел дип әйтмәс идем. Әмма тырышмый гына кайда да булмый торгандыр. Эшенең яратып башкаргач, кыенлыкларына бик игътибар бирмисең инде, – ди үзе.

Сергей Түбән Чаллыда яши, гаиләсе бар. Хуҗалыкка эшкә Надеждинода авыл хуҗалыгы училищесын тәмамлаганнан соң кайткан булган. Әтисе Петр Ильич та улының бу карарын хуплап каршы алган. Ул – тәҗрибәле механизатор һәм еш кына улына төпле киңәшләре белән дә ярдәм итә. Чагыштырмача яшь механизаторлар исәбендә йөргән Сергей үзе дә өлкәннәренең һәр киңәшенә шат. Гомумән, "Нурлат сөте"ндә тәҗрибәле механизаторларга алмашка яшь буынның килүен аеруча хуплап каршы алалар. Авыл хуҗалыгының алдагы язмышы аларның фидакарь хезмәтенә бәйле бит.



СЕРГЕЙ КОРОТКИН КУӘТЛЕ "МАККОРМИК"НЫ ИЯРЛИ

# Һөнәре "татлы" аның

**"Нурлат шикәре" җәмгыятенең дефекосатурация аппаратчысы Людмила Салминаның шикәр заводына килүенә 30 ел була.**

Моннан 3 дистә ел элек ни өчен нәкъ менә шикәр заводына килдегез, дигән сорауга җавабы гади Людмила Ивановнаның.

– Әтием белән әнием, абый да, килеиебез дә шунда эшли иде, шуңа башка эш эзләп тә тормадым, - ди бүген ул еларны искә алып. – Башта рафинад бүлегендә лаборант булып эшләдем, аннан дефекосатурация бүлегенә күчтем. Үз эшемне яратып башкарам, коллективыбыз да тату, әйбәт.

Заводта узган 30 ел гомере Людмила Ивановнага ул чагындагы предприятие белән бүгенгесен чагыштырып карарга мөмкинлек бирә. Ә аерма җир белән күк арасы.

– Ул чагында бар да кул хезмәте белән башкарыла иде бит, – ди ул. – Аннан акрынлап ярымавтоматка күчтек, соңрак процесс тулысынча автоматлаштырылды. Хәзер эшләве күпкә җиңелрәк. Бар нәрсәне дә компьютер янында утырган килеш башкарабыз, барлык параметрларны, газ бирелү нормаларын контрольдә тотабыз. Нечкәлекләрен белгән кешегә берниндн авырлыгы да юк.

Дефекосатурация бүлегендә, заводның башка участокларындагы сыман ук, эшләүчеләрдән зур җаваплылык һәм төгәллек таләп ителә. Людмила Ивановнаның эш бүлмәсендәге компьютер мониторында исә гаҗәеп күләмле дефекосатурация процессының барлык этаплары чагылыш тапкан, аппаратчы андагы схема, саннар аша эшнең барышына тулы анализ ясап бирә. Монда, һичшиксез, озак еллар буена тупланган тәҗрибәсе дә, һәр нәрсәдә тәртип яратуы да ярдәмгә килә. Ни дисәң дә, халыкка тәкъдим ителә торган продукциянең сыйфаты әнә шулай чылбырдагы бар буыннарның уртак хезмәтенә бәйле бит.

Ә авыл хуҗалыгы һәм эшкәртү сәнәгате көнен шикәр заводы хезмәткәрләре һәрвакыттагыча эш өстендә каршы алачаклар. Заводта җитештерү сезоны барганда тәүлекнең һәр сәгате кадерле: басуларда үскән татлы тамырның икътисадый нәтиҗәлелегенә ирешим дисәң, аны үзвакытында һәм сыйфатлы эшкәртү дә кирәк бит!



ЛЮДМИЛА САЛМИНА ҮЗ ЭШЕНЕҢ ЧЫН ОСТАСЫ

# Яллиннарның гаилә династиясе

**"Аграрий" хуҗалыгының Егоркино бүлекчәсе терлекчелек фермасында Яллиннарның тулы бер гаилә династиясе хезмәт куя.**

Илья Яллин – ферма мөдире, Юрий – сөт җиһазлары слесаре, Владимир һәм Юрийның тормыш иптәше Анжелика Николаевна – сыер савучылар. Райондагы бердәнбер ир-ат сыер савучы Владимир Яллин турында газета укучыларыбызга сөйләгәнебез бар инде, Илья Иванович, Анжелика Николаевна да укучыларыбызга таныш. Фермага чираттагы килүебез вакытында Юрий Иванович белән очрашырга да форсат чыкты. Терлекчелектә 6 елдан артыграк кына эшли әле ул. Әмма шул вакыт эчендә хуҗалыкның алыштыргысыз хезмәткәренә әверелергә өлгергән. Ул сөтчелек фермаларындагы сөт җиһазларының тулы тәртиптә һәм чисталыкта булуын тәэмин итә. Хуҗалык фермаларында савым көнен өч тапкыр оештырыла, савылган сөт исә сөтүткәргечләр буенча суыту җайланмаларына, аннан заводларга озатыла. Болар бар да Юрий Яллинның күзәтүе астында оештырыла, әлбәттә инде, слесарьның билгеле бер белем һәм тәҗрибәгә ия булуы таләп итә.

– Минем бурыч – сөтнең һәрчак сыйфатлы булуына ирешү, һәм моның өчен барлык шартларны да булдырырга тиешмен, - ди Юрий Яллин үзе.

Яллиннар Егоркинода яши. Тормыш иптәше Анжелика белән өч бала үстерәләр, хуҗалыклары нык, терлек-туар тоталар, бакчалары бар. Һәм моңа кадәр читтә эшләп алган Юрий авыл хуҗалыгына кайтуына бер дә үкенми. "Үз җиреңдә, гаиләң белән янәшә торып эшләве бик рәхәт", - ди ул.



ЮРИЙ ЯЛЛИН СӨТ ҖАЙЛАНМАЛАРЫ ӨЧЕН ҖАВАПЛЫ

## КЫСКАЧА

**Район хуҗалыкларында татлы тамыр уңышын җыю дәвам итә.** Кичәге көнгә хуҗалыкларда барлык мәйданнарның 69 процентыннан шикәр чөгендере җыеп алынган, бер гектарга уртача уңыш 318 центнер тәшкил итә.

**Районда шул көннәрдә кукурузны силоска салу төгәлләнәчәк.** Быел 42 мең тоннадан артыграк азык әзерләнгән, ул бер баш шартлы терлеккә 26,9 центнер азык бирәмлегә туры килә.

**Быел районда техник культуралардан көнбагышка зур игътибар бирелде.** Ул 7 мең гектарга якын, бу узган елгыдан бермәбер артык. Хәзер район игенчеләре көнбагыш суктыру белән мәшгуль, ул 1478 гектардан җыеп алынган инде (21 процент). Уртача уңыш 11,4 центнер тәшкил итә.

**Сәхифә язмаларын Лилия МӨБАРӘКШИНА әзерләде. Автор фотолары.**

СЕЗ БЕЗГӘ КЫЗЫКЛЫ

# Броня нык кулларны ярата



**Күптән түгел нурлатлы Аркадий Савинов гадәт буенча туганнары һәм якыннарыннан Танкистлар көне уңаеннан котлаулар кабул итте. Бу тыйнак бәйрәм дистәләгән механиклар һәм төзәүчеләр тәрбияләгән танк командиры өчен бик тә якын.**

1965 елның октябрендә Аркадий Савинов Татарстаннан һәм Башкортостаннан алынган яшь солдатлар составында Көнбатыш Украинага хәрби хезмәткә озатыла. Бер елдан соң механик-йөртүчеләр курсын тәмамлауга, үзе солдатларны Т-34 серләренә өйрәтә башлый. Ел дәвамында ул 24 механик әзерли, аларны Мисырга озаталар. Ә 1967 ел ахырында хезмәттәшләре белән аны "Освобождение" киноэпопеясында катнашырга чакыралар.

– Безнең танклар катнашында хәрби хәрәкәтләр кадрлары Лутава авылы янында төшерелде. 20 елдан соң да сугыш безнең күз алдына куркыныч күренеш булып килеп басты. Ә фронтовикларга ничек булды икән.., – дип уйчан гына хатирәләргә бирелде әңгәмәдәшем. Шул ук елны ул Киевта Октябрь революциясенең 50 еллыгы уңаеннан үткәрелгән тантаналы парадта да катнаша. Бүген ул совет танкларын фанер муляжлар ярдәмендә дошман танклары итеп үзгәртүләрен, ә солдатларның немец формасын кияргә теләмәүләрен бераз елмаеп искә ала. "Менә бит ул ватанпәрвәрлек", – ди Аркадий Афанасьевич.

Фильмны төшереп бетерү өчен хәрби техниканы экипаж белән бергә Алабино шәһәренә күчерәләр. Шулай итеп, Аркадий Савинов Мосфильмның төшерү базасына эләгә. Янә сугыш күренешләре, бу юлы чын "Тигр"ларга каршы. Аларны махсус фильм өчен Харьков заводында җитештерәләр, һәм Савиновка әле янә солдатларны идарә итәргә өйрәтергә туры килә. "Тигр"ларны Т-34ләр озатуында Галицыно-Апрелевка трассасы буенча техкарауга алып барганда, тукталышта торучыларның нинди тавыш күтәрүләрен әле дә онытмый. Үз җирендә фашист танкларын кемнең күрәсе килсен?

– Кемдер балаларын кысып кочаклап, павильоннар артына качты, кемнәрдер кар атты, йодрык күрсәтүчеләр дә булды. Гитлерчыларның бәрел керүләре күз алларыннан китмәгән иде бит әле, - дип искә ала якташыбыз.

Кино төшерү турында истәлекләр инде саргаеп бара торган фотоларда да саклана. Аларның күбесе "Освобождение"дә төшкән һәм Аркадий Афанасьевич фронтовикларның хәрби дан урыннары буйлап сәяхәт иткән танк фонында ясалган. Хезмәт узганнан соң ул Түбән Камага комсомол төзелешенә китә, ә бер елдан узенең күптәнге хыялын тормышка ашырып, Алабуга музыка училищесына укырга керә. Шулай итеп, баян аның гомерлек юлдашына әверелә.

Нурлатка Савиновлар 1972нче елда килеп төпләнәләр. Гаилә башлыгы 30 елдан артыграк "Пчелка" балалар бакчасында музыка җитәкчесе булып эшли, мәктәптә дә дәресләр алып бара. Сәнгать белән бергә спортка да урын табыла. "Танкистлар әйтмешли, броня нык кулларны ярата", - дип елмая Аркадий Афанасьевич. 1975нче елда ул Александр Агафонов белән берлектә шикәрчеләр микрорайоны стадионында сәламәтлек төркеме булдыра. Ул 20дән 60 яшькә кадәрге 50ләп кешене берләштерә. Көн саен иртәнге 7нче яртыда алар зарядкага җыела торган булалар. Кышын исә Аркадий Савинов чаңгыга баса. 40 ел дәвамында төрле ярышларда катнаша. Ә хәзер оныклары һәм аларның дусларында спортка карата мәхәббәт тәрбияли. Аларны стадионда еш очратырга була.

Аркадий Афанасьевичның күңел түрендә шигърияткә мәхәббәт тә бар икән әле. Монысы сөйләшкән вакытта, ул үзе хезмәт узган елларда язган дуртьюллык шигырьне укыгач, ачыкланды. Ул чагында аны танкның бөтен экипажы яттан өйрәнгән була. Якташыбыз Танкчылар көнендә аның илебезнең төрле төбәкләренә сибелгән хезмәттәшләре тагы бер кат исләренә төшерүенә ышана.

– Кайчан да булса дуслар белән очрашып, ул елларны бер искә төшереп утырырбыз әле, - дип өметләнә әле Аркадий Афанасьевич.

**Маргарита ЛИТТА**

БЕЗНЕҢ КОНКУРС

## Песиебез Мурка

**Безнең өебездә Мурка кушаматлы песи яши.**

Ул бездә 3 ел инде. Аны минем туган көнемә әбием бүләк иткән иде. Кара төсле, йомшак йонлы, ягымлы песи баласы хәзер матур булып үсеп җитте. Холкы аның бәйсез, горур. Үзен кулда тотарга, сыйпарга, иркәләргә билгеле бер вакытта гына рөхсәт итә. Әгәр туйдырсак, канәгатьсезлек күрсәтә башлый, тырнарга яки тешләргә дә күп сорап тормый.

Песиебез үз йонын яларга ярата. Ул ярты сәгатьләп юынырга мөмкин. Дәресләремне эшләгәндә, ул өстәл өстендә утырып, минем хәрәкәтләремне игътибар белән күзәтә.



Минем фикеремчә, әлеге җан ияләренә карата сабыр, ягымлы булырга, аларны яратырга кирәк.

Мин үземнең йомшак йонлы песиемне бик яратам!

**Камилла МӘҮЛЕТОВА,** 4нче мәктәпнең 4Б сыйныфы укучысы.

## Тугры Рэкс



**Безнең өебездә сакчы эт Рэкс яши.**

Минем дүрт аяклы дустым бик тугры, әмма вакыты белән зыян салырга да мөмкин. Ул мине мәктәптән каршы ала һәм шатланып өрә. Рэкс "Утыр!", "Ят!", "Тәпиеңне бир!" кебек төрле әмерләр дә үти.

Юындырганнан соң ул ишегалдында чабып йөри һәм барлыбызның да аякларыбызга ябыша. Еш кына минем әйберләремне кимерә. Аның төрле шаянлыкларына да карамастан, мин этемне бик яратам, ул минем беркайчан да хыянәт итми торган тугры дустым.

**Алия РӘХМӘТУЛЛИНА,** 4нче мәктәпнең 4Б сыйныфы укучысы.

ГАДӘТТӘН ТЫШ

## Янгын беркемне дә аямый

**6 октябрьдә** Яңа Тумбада торак йорт тулысынча янып беткән. 1954 елгы ир-ат һәм 1948 елгы хатын-кыз тәтенгә тончыгып үлгәннәр. 125нче янгын частенең диспетчер службасына сигнал иртәнге 4ләр тирәсендә керә. Нурлат районы күзәтчелек эшчәнлеге бүлегендә хәбәр итүләренчә, йортка газ үткәрелмәгән булган, хуҗалар җылынырга теләп, электр җылыткычын кабызып калдырганнар булса кирәк.

– Янгынны авыл җирлеге башлыгы Леонид Осипов күреп ала, алар улы белән бергә, янучы йортка кереп, кешеләрне коткарырга тырышалар, – ди ОНДның өлкән инспекторы Әлмарис Талипов. – Сигнал буенча Нурлаттан Тумбага 4 махсус техника чыгып китте. Янгын сүндерүгә төп көчләр килеп җиткәнче, авыл җирлеге башлыгы "Яңа Тумба" ирекле янгын отрядын эшкә җикте, күршедәге корылмаларны һәм урман массивын саклауны, янган төзелеш конструкцияләрен сүтүне оештырды.

**5 октябрьдә** Ерепкинода – чүп-чарга, Урта Камышлыда кипкән камышка ут каба. Сәбәбе – ут белән саксыз эш итү.

**4 октябрьдә** 13 сәгать 15 минутта 125нче янгын частена Якты Күлдән шәхси хуҗалыкларның берсендә печән кибәне януы турында шалтыраталар. Янгын тәмәке тартканда саксыз эш итү нәтиҗәсендә килеп чыккан.

**3 октябрьдә** 15 сәгать 05 минутта 125нче янгын частена Кычытканлыда салам тутырылган йорт яны корылмаларының януы турында хәбәр керә. Сәбәбе – электр чыбыкларының төзек булмавы.

**Сирень СӘМӘРХАНОВА**

СУД ЗАЛЫННАН

## Җәзадан җиңел котылды

**Җиңел табыш артыннан куган кайбер шәхесләр күп нәрсәгә, шул исәптән бу хакта бернидән хәбәрдар булмаган кешеләргә янган аракы сатаргa да сәләтле.**

Мәсәлән, ТРның Нурлат районы суды куллануучылар сәламәтлеге өчен куркынычсызлык таләпләренә җавап бирми торган спирт кушылган продукция сатуда гаепләнүче хатын-кызга карата хөкем чыгарган.

Суд утырышында ачыкланганча, гражданка А. 2015 елның гыйнварында Самара өлкәсендә куллануучылар сәламәтлеге өчен куркынычсызлык таләпләренә җавап бирми торган спирт кушылган сыеклык сатып ала. Әлеге сыеклыкны ул Нурлат районына алып кайта һәм аракы дип, 5 литрын 500 сумга гражданка Б.га сата.

Кылынган җинаятьнең характеры, аның иҗтимагый куркынычлык дәрәҗәсе, гаебен тулысынча таныган гаепләнүченең шәхесе һәм гаепне җиңеләйтә торган шартларны истә тотып, суд гражданка А.га җәза рәвешендә 20000 сум күләмендә штраф салды. Шуның белән бергә РФ Дәүләт Думасының Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан амнистия турындагы карары нигезендә, гаепләнүчене билгеләнгән җәзадан азат та итте.

**Алия ГЫЙЛЬМЕТДИНОВА,** судья ярдәмчесе

Күбрәк ЯҢАЛЫКЛАРНЫ NURLAT-TAT.RU САЙТЫНДА УКЫЙ АЛАСЫЗ

# ТӨРЛЕ. БЕЛДЕРҮЛӘР. РЕКЛАМА



Автор фотосы

## Көр күңелле ветеран

**5 октябрьдә Нурлатта яшәүче Гатиннар гаиләсендә иртән-иртүк бәйрәм кәефе хөкем сөрде.**

Көне буе Бөек Ватан сугышы ветераны Мирсәет ага Гатинны котлап телефон шалтырады, кунаклар килде. Юбилярны гомер бәйрәме белән котларга район башлыгы урынбасары Флюра Ногманова да килгән иде. Флюра Рәшитовна Мирсәет агага район башлыгы Равил Кузюровның бүләкләрен тапшырды, РФ Президенты Владимир Путинның мөрәҗәгатьнамәсен укыды. Юбилярны котларга районның ветераннар Советы рәисе Разия Садретдинова да килгән иде.

Елмаеп бүләкләрне кабул иткән Мирсәет ага бүгенге көненә бик шөкерана итә. Озын гомерле булуының серен исә юбиляр хәрәкәттә, киң күңелле булуында күрә.

Фома авылы егете Мирсәет ага 1943 елда, җидееллык мәктәпне тәмамлаганнан соң фронтка китә. Зенит-артиллерия полкында хезмәт итә һәм якташлары, авылдашлары белән Курск дугасына кадәр барып җитә. Фронттагы батырлыклары өчен Мирсәет ага Ватан сугышы ордены һәм бик күп медальләр белән бүләкләнә. Үзенең фронтташ дусларын бабай әле дә онытмый. 1995 елда Тула шәһәренә барып, фронтташ дусты белән Җиңү бәйрәмен дә каршы ала.

Тормыш иптәше Сәрия апа, балалары һәрвакыт янында, хәзер инде онықларына куанып яшиләр. 90 яшенә җитсә дә, Мирсәет ага оптимист булып кала белә.

**Зилия ӘКСАНОВА**

## Музей тормышы кайный

### Дипломлы булдык

**Ел саен апрель азагында республикабызның мәдәният министрлыгы һәм музейлар ассоциациясе «Татарстанда музейлар язы» акциясе үткәрә.** Габдулла Кариев музее Нурлат коллегалары белән бергә чарада актив катнаша. Быел, мәсәлән, бу атналык Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышланган иде. Акция тәгәлләнүгә, фотолар белән бизәлгән отчетыбызны Казанга юлладык. Эш нәтиҗәләре буенча, сентябрьдә районыбызның ике музее диплом белән бүләкләнде.

### Алабугага сәяхәт

**Татарстан Милли музее быел 120 еллык юбилеен бәйрәм итә.** Сентябрьдә ул төрле илләрдән килгән һөнәрмәннәрне җыеп, халыкара форум уздырды. Музейлар ассоциациясе белән берлектә, тәҗрибә уртаклашу өчен, берничә маршрут буенча сәяхәт тәкъдим ителде. Нурлат районы музее җитәкчеләре Алабуга музей-тыюлыгына барды. Анда үткәрелгән мастер-класслар, экскурсияләр, кунакларны каршы алу, шәһәрне тәкъдим итү – болар барысы да бәяләп бетергесез тәҗрибә мәктәбе.

### Авылдашыбыз эзеннән

**15 сентябрьдә Ижевск шәһәреннән хат алдык. "Гайшә апа Баһаветдинова туганнарына" дип салган хатымны Әгерҗе районы Кадыбаш авылының мәрхәмәтле авыл җирлеге башлыгы Ижевск шәһәренә үк илтеп, килене белән оныгына тапшырган.**

Бу хат Әгерҗе белән ике арасы бер ай эчендә әйләнеп кайтты. 35 ел элек Флюра Хәлим кызы Сәгыйровага килеп, соңгы елларда гына табылган беренче хатның тарихы шулай тәмамланды. Ижевскидан килгән хәбәрдән шуны белдек: беренче хат авторы – күренекле партия һәм совет эшчесе, мәктәп директоры, туган як тарихын өйрәнүче авылдаш апабыз Гайшә Баһаветдинова 1992нче елда вафат булып, Кадыбашта җирләнгән. Аның үзе һәм абыйсы турында әүвәлге хатта язган истәлекләре хәзер музейда саклана. Исемнәре авылыбызның мактаулы кешеләре исемлегендә лаеклы урын алыр.

### Тамырларны барлыйбыз

**Чистай каласыннан 18 сентябрьдә килгән илчеләрнең йомышлары әлегә ачык кала.** Морасада туган Әхмәтова Закирә апаның тамырларын бергә эзлибез. Ул 1926нчы елда вафат булган, хәлле, бай гаиләдә үскән. Әтисе кибет тоткан. Аның кызы Сания Минаповна 1923нче елда туып, 1998нче елда вафат булган. Бу гаиләдә бик күп элеккеге фотолар сакланып калган. Шуларның күчермәләрен музейга биреп, безне сөендерделәр. Бу гаилә белән дә дуслык җепләре ныгыр, сорауларга җавап табылыр, иншалла.

**Люзия ВӘЛИУЛЛИНА, Габдулла Кариев музее директоры**

### Искә алыгыз

13 октябрьдә кадерлебез **Камил Халим улы ХӘЙРУЛЛИННЫҢ** якты дөньядан китүенә 40 көн була. Без якыннарын әрнеткән үкенечле югалту бер генә минутка да исебездән чыкмый, кадерлебезнең кыска гына гомерендә кылган игелекләрен, якты күңелен, эшчән, сабыр холкын сагынып искә алучылар күплеген әле дә тоеп торабыз. Аны соңгы юлга озатканда янәшәбездә булган хезмәттәшләре – "Нурлатнефть" НГДУсының ППД цехы коллективына, Колбай Мораса авылы халкына, туганнарыбызга, дусларыбызга һәм кайгыбызны уртаклашкан һәммә кешегә рәхмәтебез көннән - көн арта бара. Аллаһ сезне авыр кайгы-хәсрәтләрдән сакласын, игелегегез икеләтә изгелек булып кайтсын. Бу көннәрдә Камилебезне игелеге белән искә алсагыз, аның рухына дога булып ирешер иде.

**Әнисе, туганнары.**

Приглашаем на постоянную работу в нефтедобывающую компанию ГК ОЙЛЭКТ
**(ООО "ТНГК-Развитие")**:
*- Инженера-строителя (с опытом работы)*
*- Электрогазосварщика 5 разряда (с опытом работы).*
Место работы: г. Нурлат.
Телефон отдела кадров: (843)200 99 98,
Лидия Сергеевна
**Резюме направлять на эл.почту: mardanovals@oilect . ru**

### НЕДВИЖИМОСТЬ

*2-комнатная квартира, мкр. 50 лет Победы, 5, 1 этаж (мебель, рядом школа, детский сад), 1500 тыс.руб. Т. 8-9274-322-585.

*коттедж в с. Тюрнясево. Т. 8-919-643-48-04.

*дом. Т. 8-927-462-17-01.

*дом в мкр. афганский. Т. 8-917-915-60-23.

*коттедж, ж/д, все есть, недорого. Т. 8-937-600-48-07.

*2-комнатная квартира, ул. Нефтяников, Т. 8-927-420-96-58.

*дом без отделки, ул. Рябиновая. Т. 8-927-406-17-05.

*2-комнатная квартира, центр. Т. 8-905-039-83-04.

*1/2 доля в 2-комнатной квартире по ул. Самаренкина, 9. Т. 8-937-610-48-70.

*капитальный гараж с погребом, пер. Заводской. Т. 8-927-445-00-14.

*капитальный гараж возле школы №4 (имеется погреб). Т. 8-9274-22-89-16.

*участок с фундаментом (подвальное помещение готово), ул. Товарищеская. Т. 8-927-428-85-65.

*коттедж. Ул. Дачная, 28. Т. 8-9270-47-41-24.

*дом. Варианты. Т. 8-919-684-40-03.

*2-уровневая 4-комнатная квартира по ул. Промышленная. Т. 8-9297230-707.

*1-комнатная квартира. Т. 8-927-473-25-64.

*1-комнатная квартира, новая, 1 этаж, 900 тыс.руб., инд. отопление 40 кв.м. Т. 8-937-610-48-70.

*1-комнатная квартира, малосемейка, мкр. Яшлек, 3 этаж, 580 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.

*комната в общежитии, 200 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.

*коттедж новый, мкр. Верхний Нурлат, 130 кв.м, баня, гараж, 4,5 млн. руб. Т. 8-937-610-48-70.

*жилой дом, ул. Синдрякова, 150 кв.м, 2,8 млн.руб., требуется ремонт. Т. 8-937-610-48-70.

*коттедж, пер. Промышленный, 150 кв.м, 3,6 млн.руб., гараж, баня, бассейн. Т. 8-937-610-48-70.

*3-комнатная квартира, ул. Ленинградская, 2А, 2 этаж, 60 кв.м, 1 млн.руб. Т. 8-937-610-48-70.

*2-комнатная квартира, мкр. Яшлек, 1 этаж, 44 кв.м, 1 млн.руб. Т. 8-937-610-48-70.

*2-комнатная квартира, 5 этаж, 50 кв.м, 820 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.

*2-комнатная квартира, ул. Электростанции, 5 этаж, 49 кв.м, 1,1 млн.руб. Т. 8-937-610-48-70.

*жилой дом, д. Русская Менча, 1 млн. руб., 100 кв.м. Т. 8-937-610-48-70.

*жилой дом, мкр. ж/д, 50 кв.м, 720000 руб. Т. 8-937-610-48-70.

*коттедж элитный в престижном районе, 6 млн.руб. Т. 8-937-610-48-70.

*2-комнатная квартира, мансарда, 50 кв.м, 650 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.

*земельный участок, д. Пушкино, 80 тыс.руб. Т. 8-937-610-48-70.

*2-комнатная новая квартира, ж/д, 50 кв.м, 2 этаж, 1220000 руб. Т. 8-937-610-48-70.

*3-комнатная квартира, мкр. Яшлек, 5 этаж, 1180 тыс. руб. . 8-937-610-48-70.

*3-комнатная квартира, ул. Кариева, 3 этаж, балкон, лоджия, 70 кв.м. Т. 8-937-610-48-70.

*3-комнатная квартира с ремонтом, ул. Нурлатская. Т.8-927-037-48-98.

*1-комнатная квартира. Т. 8-917-932-75-06.

*1-комнатная квартира в мкр. Яшьлек. Т. 8-927-473-25-64.

*земельный участок, 15 соток, ул. Халикова. Т. 8-919-642-62-49.

### АВТОТРАНСПОРТ

*«ВАЗ-2110» 2006 г/в, в отличном состоянии. Т.8-937-626-71-18.

*«Калина» универсал, 2011 г/в. Т.8-927-247-25-28.

*мини-трактор + прицеп. Т. 8-987-409-93-48.

*«КамАЗ», 1992 г/в. Т. 8-927-446-76-46.

*«Дэу Нексия», 2008 г/в, 150 тыс.руб. Цена договорная. Т. 8-927-401-41-92.

*«ВАЗ-2107», 2007 г/в. Т. 8-917-265-70-19.

*«ВАЗ-2106», 2000 г/в, цена договорная. Т. 8-927-451-98-08.

*«Рено Меган III» 2014 г/в, светло-серый. Т.8-917-929-82-26.

### ДРУГОЕ

*металлическая печь для бани. Т.8-937-042-11-51.

*куртка-парка. Т. 8-927-429-07-83.

*высокоудойная корова, д. Ахметкино. Т.8-927-673-44-20.

*мягкая мебель (диван, 2 кресла-кровати), в отличном состоянии. Т.8-927-671-53-52.

*мягкая мебель, стол-тумба, телевизор. Т.8-927-037-48-98.

*корова, телята. Т.8-937-993-62-50.

*бычки, молодняк. Т. 8-937-453-40-91.

*сахар-2290, мука-970, магазин «Юмарт» . Т. 8-927-445-68-55.

*доски (осина, сосна), брусья. Доставка. Т. 8-937-003-84-85.

*телята, сено, солома, доставка бесплатно. Т.: 8-937-343-80-22, 8-909-345-99-77.

*корова. Т. 8-937-29-15-310.

*мелкая картошка. Т. 8-937-297-31-53.

*сруб дома осиновый, размер 6х8, недорого. Т. 8-927-475-94-24.

*лошадь. Т. 8-927-032-35-93.

*б/у пластиковые окна 4 шт. (1,32х1,42), трубы НКТ d-73 мм. Т.:8-937-288-42-67, 8-987-239-14-54.

*косилка роторная. Т. 8-927-474-54-57.

*поросята. Т. 8-927-241-58-83.

*гаражные ворота. Т. 8-937-594-02-94.

*поросята 1 месяц 10 дней. Обращаться в д. Салдакаево, к Сандимирову Валерию. Т. 8-937-570-95-32.

*песок, ПГС от 3 тонн. Т. 8-927-244-84-71.

*корова, картошка, участок в деревне. Т.: 8-937-776-60-03, 8-927-415-57-80.

*телка (1 год 7 месяцев). Т. 8-937-599-75-23.

*красная свекла, морковь, козлята, коляска-трансформер. Т. 8-987-189-59-20.

*перегной, чернозем, ПГС, грунтощебень. Т. 8-927-463-63-17.

*перегной, чернозем, бут, песок, цемент. Т. 8-937-28-74-90.

*бычки, телята разного возраста. Т. 8-927-483-06-10. 8-917-293-27-47.

*банные камни. Т. 8-927-428-85-65.

*перегной. Т. 8-987-283-18-34.

*перегной. Т. 8-927-248-19-66.

*перегной. Т. 8-927-675-54-96.

*мягкая мебель, кресло. Т. 8-927-245-64-92.

*бычок, 10 месяцев. Т. 8-937-776-60-33.

*говядина (халяль) кусками и частями. Т. 8-927-245-32-03.

*ПГС, песок, бут, камень, жом. Т.8-927-672-31-49.

### РАЗНОЕ

*доставка: песок, ПГС, жом. Т. 8-937-583-35-80.

*штукатурно-малярные услуги, плитки. Т.8-927-047-10-21.

*наружная реклама, полиграфия. Т.8-927-429-07-83.

*услуги электрика. Т.8-937-571-28-37.

*ремонт пластиковых окон. Т.8-927-249-54-24.

*грузоперевозки. Т.8-987-006-28-73.

***ремонт, настройка: компьютеров, ноутбуков, Wi-Fi, Интернета. Т.8-937-005-14-51.**

*тамада. Т. 8-960-088-23-94

*натяжные потолки. Т. 8-9270-365-365, Алексей.

*репетиторство 8-11 классы. Подготовка к ОГЭ и ЕГЭ по химии. Т. 8-927-672-76-36.

*ремонт холодильников на дому. Т. 8-927-419-56-48.

*замена электропроводки. Т. 8-929-728-93-36.

*услуги электрика. Т. 8-987-418-35-00.

*кроем кровлю, обшиваем дома и другие строительные работы. Т. 8-927-422-26-33.

*ремонт холодильников. Т. 8-937-610-58-78.

*копаем, чистим колодцы, копаем траншеи, канализации. Т. 8-937-776-79-45.

*грузоперевозки «ГАЗель». Т. 8-937-570-60-21.

*перетяжка, ремонт мягкой мебели. Т. 8-937-570-60-21.

*шипуем резину, д. Ср. Камышла. Т. 8-937-774-34-27.

*ремонт компьютеров, установка программ. Т. 8-927-485-70-65.

*копаем, чистим колодцы. Т. 8-987-274-95-46.

*сантехника (отопление, водопровод, канализация). Т. 8-937-526-56-86.

*услуги погрузчика. Т.8-927-672-31-49.

### ТРЕБУЮТСЯ

*мастер строительного участка. Т.:9-50-52, 8-937-772-26-30.

*Вахта в Москву. сборщики, грузчики, комплектовщики (-цы), упаковщики (-цы), фасовщики (-цы), кассиры. Т.8-927-272-91-84.

*продавец в продуктовый магазин. Т.8-937-775-98-71.

*электрик. Т.:8-84342-9-33-57, 8-917-398-26-41.

*слесарь КИПиА. Т.8-917-277-02-58.

*повар. Т. 8-937-287-60-50.

*в связи с расширением производства ЗАО «Техсервис» специалист со знанием гранд-смет (высшее образование, опыт работы), электромонтер. Т.2-05-74.

*водитель на кран-манипулятор «Daewoo»*, водители на МАЗ с прицепом кат. Е. Т.: 8-937-772-26-30, 9-50-52.*«Дэу».

*водитель на «КамАЗ». Т. 8-937-594-02-94.

*грузчики. Т. 8-937-570-64-24.

*няня, домработник(-ца), учитель коррекционной школы. Т. 8-937-571-22-17.

### КУПЛЮ

***«ВАЗ», иномарки. Дорого. Т. 8-929-723-31-23.**

*АВТО. ДОРОГО. Т. 8-937-588-36-46.

*пух гусиный, мокрый, сухой, старые подушки, перины. Т. 8-987-062-55-26.

*КРС и шкуры КРС, дорого. Т. 8-927-443-05-43.

### СДАЮТСЯ

*2-комнатная квартира командировочным. Т. 8-927-671-53-52.

*2-комнатная квартира в центре на длительный срок. Т.8-937-282-85-51.

*дом, Бурметьево. Т. 8-917-266-65-18

*дом ж/д. Т. 8-939-744-15-08.

*квартира посуточно. Т. 8-927-456-05-69.

*квартира посуточно. Т. 8-927-406-11-06.

